

Габдулла Тукай дигән исемне ишетvгә, без татар халкынын боек шагыйре, татар әдәбияты классигы, публицист, яна заман татар әдәбиятына һәм әдәби теленә нигез салучы дип беләбез. Бала тугач та ин беренче туган телен ишетә, ә татар баласы беренче сvзләре белән бергә, Габдулла Тукайнын «Су анасын», «Шvрәле»сен ишетеп vсә. Ә мәктәптә исә, бу әсәрләрдән хәтта озекләрне ятлый.
Агымдагы елнын 26 апрелендә Г.Тукайнын тууына 135 ел тулу унайдан республикакvләм һәм Бо-тенроссия кvләмендәге торле чаралар уздырыла. Г.Тукайны башка милләт халыклары да vз итә.     1986 елда, шагыйрьнен тууына 100 ел тулу унаеннан, Берләшкән Милләтләр Оешмасынын Мәгариф, фән һәм культура буенча комитеты (ЮНЕСКО) бу бәйрәмне халыкара дип игълан итте.
Тукай бәйрәмен каршылаганда, атаклы язучыбызга багышлап кичәләр vтә, анын китаплары нәшер ителә, торле конкурслар, кvргәзмәләр оештырыла, интернетта «Минем Тукай» флешмоблары һәм торле чараларнын саны арта гына бара. Мордовия мәктәпләребездә дә, мә-сәлән  Атюрьево, Дубенки, Ельники, Кадошкино, Кочкурово, Ромоданово, Рузаевка, Ләмберә, Торбеево, Темников районнарындагы татар теле һәм әдәбияты ойрәнелә торганнарында, бик кvп торле чаралар vткәрелә. Шигырь сойләvчеләр конкурслары, Г.Тукай язган әсәрләренә рәсемнәр ясау, сәхнәләштереп кую, стена газеталары чыгарыла, ачык дәресләр, КВНнар vткәрелә, конкурслар уздырыла... Бу эшләрнен кvбесенә Ләмберә районы Пензятка, Рузаевка районы Татар Пешлә, Ромоданово районы Белозерье авыллары балалар бакчаларында- тәрбиячеләр, мәктәпләрдә - татар теле һәм татар әдәбияты укытучылары зур коч куялар.
«Тукай кичәләре» балаларнын кvнелләрендә шагыйрь ижатына карата ихтирам, горурлык хисләре тәрбияләvдә, яшь буынны югары әхлаклы, тирән белемле шәхес формалаштыруда зур роль уйный. Болай булгач, Тукай ижаты киләчәк буыннар тарафыннан онытылмаячак дигән фикердә без.